КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 декабрь г.Казань № 1227

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны билгеләү турында

«Урамнан тыш транспорт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге ФЗ-442 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифларны кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1227 нче
карары белән расланды

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар

| Пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүләргә бер тапкыр транспортта йөрүгә тарифлар, сум | | | Билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тариф[3], сум |
|---|---|---|---|
| метрополитен кассаларында жетон (билет) сатып алганда | транспортта йөрү өчен озак файдаланудагы билет белән түләгәндә | | |
| | 1 тапкыр транспортта йөрүгә[1] | 100 тапкыр транспортта йөрүгә[2] | |
| 30 | 27 | 20 | 30 |

---

[1] Транспортта йөрү өчен билгеләнгән сумма чикләрендә транспортта йөрүгә хокук бирә торган билет белән түләгәндә.
[2] Транспортта йөрү өчен күрсәтелгән вакыт дәвамында транспортта билгеләнгән тапкыр йөрүгә хокук бирә торган озак файдаланудагы билет белән түләгәндә.
[3] Билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу бәясе өчен түләү транспортта йөрү бәясе өчен түләүдән аерым башкарыла.

---